СОВЕТ СРЕДНЕКУШКЕТСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КӨШКӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
«25» март 2026 ел

**КАРАР**
№ 22

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2025 №505-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында «Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17 (1) статьяларына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 26.02.2026 №16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. "Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Урта Көшкәт авыл җирлеге Советының 26.04.2021 №23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Урта Көшкәт авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (14.03.2023 №72, 26.07.2023 №79, 29.11.2024 №110, 23.12.2025 №13 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«15 маддә. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру**

1. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда тапшыралар. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм форма буенча тапшырыла.

2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" Федераль закон) каралган чыгымнар хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча тапшырырга тиеш.

3. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору "Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законда һәм “Дәүләт вазыйфаларын биләүче

затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында"  Федераль законда , Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, әлеге Кодекс, Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр, әгәр федераль законнар тарафыннан дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр була.

5. Муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләрдән муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының түләү сәләтен билгеләү яисә билгеләү өчен, дини яисә башка иҗтимагый берләшмәләр, башка оешмалар, шулай ук физик затлар фондларына турыдан-туры яисә читләтелгән рәвештә иганәләр (взнослар) җыю өчен файдалану рөхсәт ителми.

6. Әлеге статья нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне ачуда яисә әлеге белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда куллануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

7. Муниципаль хезмәткәрнең «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда каралган чыгымнар хакында белешмәләрне тапшырмавы, әгәр мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булса йә белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып санала, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш.».

1.2. 12 статьяның 2 өлешендә "җирлекнең сайлау комиссияләренең," сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 24 статьяның 2 пунктында", җирлек сайлау комиссиясе» сүзләрен һәм «, җирлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.4. 30 статьяның 3 өлешендәге 1 пунктына «яисә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Президенты администрациясенең вәкаләтле бүлекчәсе тарафыннан»сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» интернет ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Урта Көшкәт авыл җирлеге башлыгы

Ю.М.Перфилов